

Яшь ленинчы

ВЛКСМның Татарстан республика комитеты һәм В. И. Ленин исемендәге пионер оешмасының республика советы газетасы

октябрь, 1990 ел. № (4163).

Бәясе 1 тиен

ЯҢА ДУС!

Яшь булсаң да, «Яшь ленинчы»,
Дус булырсың син миңа.
Яшьтәшем үк булмасаң да,
Хат язармын мин сиңа.

Дустың артты,- «Яшь ленинчы»,
Шатлан инде, уйна-көл!
Бик барасың килеп китсә —
Безгә дә кунакка кил!

Уйларбыз да, уйнарбыз да,
Шатланып, борчылырбыз.
Уртак булгач һәр кайгыдан
Бик җиңел котылырбыз.

Менә, дустым, килештек тә,
Язылдым күптән сиңа.
Башкаларны да гәҗиткә
Яздыру калды миңа.

Дуслаштык синең белән,
Кире какмассың, беләм,

Сәлам белән
Мөршидә ҖИҺАНШИНА.
Зеленодольск районы
Түбән Урысбага урта
мәктәбенең XI класс укучысы.



МӘКТӘПТӘ укулар башланган чак иде. Көннәрнең берендә редакциягә атыла-бәрелә Шәвәли кайтып керде.

— Районнан кайтып килеш әле,— диде ул.

Без, Шәвәли нинди яңалык әйтер икән дип, аны тыңларга җыендык.

(Дәвамы 2 нче биттә.)

— Менә шул,— дип дәвам итте Шәвәли.— Бер малай белән дә таныштым. «Шәвәли туган, ди,— мин «Яшь ленинчы»га язылдым»,— ди.

— Әйбәт хәбәр алып кайткансың син,— дидек без Шәвәлигә.

— Теге малай әйтә: «Минем әле энем дә бар, ди. Аңа да укырга кирәк ич!» — ди.

— Нигә, энесенә дә язылсыннар,— дип киңәш иттек без Шәвәлигә.

— Анысын гына алар үзләре дә белә. «Бәясе дә арткач, киләсе елга газета тагын да әйбәтрәк чыгачакмыни! Сан саен әкият бастырырлар микәнни!»— дип тинтерәтә икән энекәше.

Без дәррәү көлешеп җибәрдек. Мәсьәләне кабыргасы белән куйган бит әле ул малай!.. Әкият кенә бастырып чыгара башласаң, газета газета булудан туктамасмы соң! Һәм без, редакция хезмәткәрләре, киләсе елда газетада ниндирәк язмалар басылачагын сөйләп бирергә булдык. Теге малайга гына түгел, барлык укучыларыбызга!

Рәисә ЯХИНА,
фән-техника, спорт һәм хезмәт тәрбиясе бүлеге мөдире:

— И... балакайлар! Мин әле яңа тына эшкә чыктым бит бүген. Бер айга якын редакциядән аерылып, бөтенләй чит җирләрдә — Казаннан еракта ял итеп кайт та, беренче эш көнендә үк үзеңнең планнарың белән уртаклаш, имеш. Юк, алай булмый ул. Ни дисәң дә, кеше машина түгел ич. Элек әле ул уйланырга, башындагы фикерләрне тәртипкә салырга, аннары гына кулына каләм алырга тиеш. Хәер... газета эше шундый инде ул, конвейер кебек. Монда озак уйланып торырга вакыт юк. Иртәгә үк папкага материаллар сала башлыйм: «Туган ягым — яшел бишек» экология экспедициясе ничек бара, «Сугыш чоры балалары» ничек яшәгәннәр, хезмәт дәресләре сезне канәгатьләндерәме? Тагын бер планым бар. Анысын хәзергә «Сиңа әйтер сүзем бар» дигән рубрика белән биреләчәк материаллар дип торам. Менә шул. Бу планнарны ничек тормышка ашыру миннән генә түгел, сездән дә тора, укучылар. Язмаларым әйбәт килеп чыкса да, кимчелекләре булса да, миңа хат языгыз, ярыймы. Үз исемемә.

Йолдыз ҖАМАЛЕДИНОВА,
мәктәпләр бүлеге хәбәрчесе:

— Киләсе елда да газета укучыларын я елмайта, я елата торган мәкаләләр язарга [illegible] лыйм. Икенче [illegible] лым — «Алмаш» [illegible] дөньяга ешрак [illegible]. Тормышка ашма[illegible] лар түгел, билгеле. «Алмаш» дигәннән, аның исемен үзгәртү хакында да сөйләшә башладык. Сез ничек уйлыйсыз, башлангыч сыйныф укучылары өчен чыга торган сәхифәне ничек атасак, әйбәтрәк булыр икән? Тәкъдимнәрегезне көтәбез. Тиздән Лениногорск якларына юлга чыгып китәргә җыенам. Бәлки, очрашырга газета хакында бергәләп тә сөйләшербез әле.

Атлас ГАФИЯТОВ,
спорт бүлегенең өлкән хәбәрчесе:

— *АТАКЛЫ хоккейчы Зиннәтулла абыегыз БИЛАЛЕТДИНОВ белән очрашырга телисезме? Сизеп торабыз, хоккей яратучы бик күп малайлар: «Әйе!» — дип әйтәчәк. Ул гына да түгел, Вәгыйз ҺИДИЯТУЛ-*

ЛИН, Хәбил БИКТАШЕВ, Равил КАШАПОВ, Айрат ХАМАТОВ, Светлана ДЕМИНА, Надежда КИБАРДИНА кебек дөньяны шаулаткан спортчылар белән дә очрашу көтә сезне. Әйе, әйе, сезнең белән, әйе, газета аша.

Илсөяр ИКСАНОВА,
әдәбият-сәнгать бүлеге хәбәрчесе:

— КИЛӘСЕ ЕЛДА балалар иҗатына зур урын бирәчәкбез. Өлкән язучыларыбыз повестьлар-хикәяләр, әкиятләр, шигырьләр язарга вәгъдә иттеләр. Мәктәп сәхнәсендә куярлык пьесалар да әзерләдек.

Тагын бер яңалыгыбыз бар. Шушы саннан без пәйгамбәрләр тарихын бирәбез. Киләсе елда исә пәйгамбәрләр хакындагы кыйссалар дөнья күрәчәк. Ул борынгы кыйссаларны Фәнни Үзәк галимнәре Марсель ӘХМӘТҖАНОВ, Фәрит ЯХИН һәм Нәҗип ИСМӘГЫЙЛЕВ әзерләячәк.

Әлбәттә, атаклы сәнгатькәрләребез, балалар иҗат коллективлары белән таныштыруны дәвам иттерәчәкбез. «Яңа китап — яңа дус» сәхифәсендә исә сезне яңа китаплар белән дуслаштырырбыз.

Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
җаваплы сәркатип ярдәмчесе:

— ГАЗЕТА ЧЫГАРУ җиңел эш дип уйлыйсызмы? Авыр да, рәхәт тә. Машинистка язып биргәнне макетка салып, типографиягә төшереп җибәргәч, башлана инде аның михнәтләре. Газета чыгаручы материалларны, рәсемнәрне дөрес, матур итеп кую өчен тырыша. Полосалар әзер булгач, корректор көн буе, газета хатасыз чыксын дип, хата тикшерә.

Рәхәтлеген икенче көнне, өр-яңа газетаны кулыңа алгач, сизәсең. Шул рәхәтлекнең иң зурысы сезнең шатлыкны тою, укучылар! Шикләнмим, киләсе елда да без сезне шатландыру өчен тырышачакбыз. Менә күрерсез!

Фирдәвес БӘШИРОВА,
хатлар бүлеге хәбәрчесе:

— ЯҢА ГЫНА, үскәннәрем, остаханәгә барып, Борһан бабаегыз белән газета битләрендә малайлар өчен файдалы киңәшләр почмагы ачып җибәрсәк дип сөйләшеп кайттык. Аны «Остаханә» дип атарга булдык.

Ил тоткасы — ир, дип белми әйтми ич халык. Илебез киләчәге, күп тә үтмәс, әле генә «Яшь ленинчы»ны укып йөргән малайлар, яшүсмерләр кулына күчәр. Аларның һөнәрле, акыллы булып тәрбияләнүендә аз булса да безнең өлеш тә булыр.

ӘТКӘМ-ӘНКӘМ БҮЛӘГЕ

АНА ТЕЛЕМ, ТУГАН ТЕЛЕМ,
СИН — ТОРМЫШНЫҢ ТЕРӘГЕ,
МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ КАДЕРЛЕ
ӘТКӘМ-ӘНКӘМ БҮЛӘГЕ.

ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНЕГЕЗ,
КҮҢЕЛ БИРЕП УКЫГЫЗ.
«ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» ГАЗЕТАСЫ
БУЛЫР ЯКЫН ДУСТЫГЫЗ.

Абдулла БИКБУЛАТОВ.

Башкортстан. Октябрьск шәһәре.

Пәйгамбәрләр тарихы

قصص الانبياء

ХАЛЫК СӨЙЛӘШКӘНГӘ колак салыгыз әле: ничек дип әйтә ул? «Хәерлегә булсын!»— диме? Әйе, шундый изге теләктә яши ул. Табигатьтәге үзгәрешләрне күреп тә, иҗтимагый үзгәрешләр көтелсә дә: «Хәерлегә булсын!»— диләр.

1917 елгы Октябрь революциясе дөньяның астын-өскә китереп ташлады. Кешелек тарихында беренче тапкыр өр-яңа җәмгыятькә нигез салынды.

— Хәерлегә булсын! — дип теләде халык.

Хәерле булсын!

Социалистик җәмгыятьне Аллаһы Тәгалә ярдәменнән башка гына төзергә ниятләделәр. Хәер, Аллаһы Тәгаләдән ничек ярдәм сорыйсың инде?! Аның юклыгын әйтеп нәгърә ордылар. Бәй, Аллаһы Тәгалә юк икән, димәк, юк нәрсәгә ни өчен табынырга соң әле? Сүтеп-җимереп ташларга кирәк ул гыйбадәтханәләрне.

Һәм нәкъ шулай эшләделәр дә...

Мәчетләр айсыз-манарасыз калды. Бушаган бинаhave бо клубларга, төрле әйберләр саклый торган келәтләргә әйләндерделәр.

— Хәерлегә генә була күрсен...— диде халык.

Егерменче еллар ахырында, утызынчы елларда дини китапларны өеп-өеп яндырдылар. Дини китаплар белән бергә гарәп хәрефендә басылып чыккан әдәби китаплар да, гыйльми әсәрләр дә утка очты. Дин әһелләрен Сталин концлагерьларында җәзалап үтерделәр.

Борынгы заманнардан безгә мирас булып калган әдәбият-мәдәният һәйкәлләре әнә шулай вәхшиләрчә юкка чыгарылды.

— Хәерлегә булсын...— диде халык, сыгылып төшеп яшь түкте.

Динне шул дәрәҗәдә хөкем итәргә ярый идеме соң?

Мәгълүм булганча, безнең бабайларыбыз — Идел буе болгарлары мөселман динен моннан мең ел элек, төгәлрәк итеп әйткәндә, 922 елда кабул итәләр. Димәк, татар халкын мең ел буе мөселман дине тәрбияләгән. Дини риваятьләргә нигезләнеп шагыйрьләребез поэмалар иҗат иткәннәр. Болгар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен генә мисалга алыйк. Поэманың үзәгендә — Йосыф пәйгамбәр башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләр ята. 1212 елда иҗат ителгән поэма ничәмәничә гасырлар буе татар халкын әхлакый яктан тәрбияләде, рухи яктан гариплэнгән кешеләрне дәвалады, сихәтләндерде, савыктырды.

Мондый мисалларны әдәбиятыбыз тарихыннан күпләп китерергә мөмкин. Гомумән, татар халкының тарихын мөселман диненнән башка күз алдына

китерүе дә кыен.

Дини риваятькә нигезләнеп иҗат ителгән соңгы әсәр — Һади Такташның «Җир уллары трагедиясе». Шуннан соң татар әдәбиятының гасырлар дәвамында килгән горефендә өзеклек башланды. Борынгы чорда иҗат ителгән әсәрләрне без хәтта аңламыйбыз да. Кем ул Йосыф пәйгамбәр, ниләр кылып йөргән ул? Кем ул Кабил белән Һабил? Такташ ни өчен алар турында поэма язарга уйлады икән? Кабил белән Һабил турында сөйләп, нәрсә әйтергә теләде икән шагыйрь?

Сораулар җавапсыз кала...

Хәзер, үзгәртеп кору чорында, дингә ышанучылар акрын-акрын үз гыйбадәтханәләренә әйләнеп кайта башладылар. Алар үз акчаларына мәчетләрне төзекләндерәләр, манараларын торгызып, очына ай куялар. Кайчандыр динне сүгеп йөргән кайбер әһелләр дә мәчеткә йөри, намаз укый.

Алайса, без ни өчен мөселман динен тәнкыйтьләгән идек соң? Белмибез ләбаса без аның тарихын. Шулай булгач, динне тәнкыйтьләргә, «Аллаһы Тәгалә юк ул!»— дип нәгърә орырга хакыбыз бармы соң безнең? Әлбәттә, юк.

Дин ул аерым бер халыкларны үзара берләштерү чарасы булган. Мәсәлән, мөселман дине гарәп һәм фарсыларны, төрки халыкларын бер байрак астына туплаган. Соңрак мөселман дине башка халыкларга да үтеп кергән. Аллаһы Тәгалә тарафыннан җиргә иңдерелгән изге затлар — пәйгамбәрләр имансызларны, ягъни потка табынучыларны, туры юлга керткәннәр. Шуңа күрә дә дин дәресләребезне пәйгамбәрләр тарихыннан башлауны мәгъкуль күрдек. Сез исә, кадерле укучыларыбыз, изге теләктә йөрегез.


— Хәерлегә булсын!— дип әйтергә өйрәнегез.

Пәйгамбәрләр тарихы белән танышканнан соң, мөселман диненең барлыкка килүен, аның төрле халыклар тарихындагы әһәмияте хакында дәресләр үткәрербез.

Изге сәгатьтә!








Рәсемнәрдә: «Бисмилла»ны язу үрнәкләре.



ТУГАН ТЕЛ

Туган телеңне белмәсәң,
Калырсың җырсыз кебек,
Матур җырлар җырлана
бит
Туган телдә иң элек.

Туган телеңне онытма,
Иң изге туган телең.
Туган телең исән булса,
Шат үтәр һәрбер көнең.

Үз телеңне ихтирам ит,
Бик күп телләр белсәң дә,
Туган илдә булсын уең,
Чит илләрдә йөрсәң дә.

Гүзәл МОСТАФИНА,
Кукмарадагы 1 нче урта
мәктәп укучысы.

САГЫНАМ

Сагынам мин абыемны —
Кат-кат укыйм хатларын.
Өстәлемә рәсемнәрен
Тезеп куям да барын.

Күз алдыма килеп баса
Елмаеп торган килеш. —
Солдат хезмәтен
тәмамлап
Әйләнеп кайткан, имеш.

Ул чынлап та кайтсын иде,
Их, керсен иде килеп!
Барыбызны
шатландырып,
Өебезгә ямь биреп.

Луиза ТӨХФӘТУЛЛИНА,
Кукмара районы
Зур Сәрдек
урта мәктәбе укучысы.

Аю мәктәпкә барды...



Урманда яшәү туйдырды
Нәни аю баласын.
Кулына сумкасын асып,
Мәктәпкәме барасы?

Беркөн букча үргән иде
Җиләк-гөмбә җыярга,
Бүген шуны юллап алды
Китап-дәфтәр тыгарга.

Әтисеннән кача-поса
Китте авыл ягына.
Мәктәпкә барса да үзе,
Уе урманда гына.

Барып керсә, бу мәктәптә
Бардыр йөз меңләп кеше.
Курыкты, тирләп пеште ул,
Бәрелә тешкә-теше.

Урманкаен сагынудан
Килә аның елыйсы...
Әбисенең бал бәлешен,
Әй, бер генә ялыйсы!

Чыгып качмак булды
моннан,
Юлны тапмый һич кенә.
Сискәнеп уянды аю:
Ярый әле төш кенә...

Кая гына китсәң дә син,
Тарта шул туган туфрак.
Әйдәгез, бу турыда без,
Уйланыйк әле ешрак.

Венера МӨКИМОВА,
Актаныш районы
Татар Ямалы
урта мәктәбе укучысы.

Кеше бул!

Әкият



БОРЫН-БОРЫН ЗАМАНДА яшәгән ди сандугач. Ул көне-төне сайрап туймый ди. Бөтен кеше аны ярата икән. Тик Ләйлә исемле кире кыз гына яратмый ди аны. Беркөнне ул урамга чыгып сандугачка бәйләнгән:

— Нигә син гел сайрыйсың, кеше кебек сөйләш,— ди икән. Сандугач аңа:

— Башта син минем кебек җырла, шуннан соң мин дә синеңчә сөйләшермен,— дигән. Кыз сандугач кебек җырларга тырышкан, булдыра алмаган.

Шуннан бирле әйтәләр, имеш: кеше икәнсең, кеше бул!

Гөлгенә ЛОТФУЛЛИНА,
Азнакай районы Әсәй урта
мәктәбе укучысы.

ҖЫЛЫ ЯККА ОЧАЛАР

ЗООЛОГИЯ дәресендә укытучы Илнурга сорау бирә:

— Илнур, кыш көне бакалар кайда яши?

Малай аны-моны уйламыйча:

— Җылы якка очалар,— дип җавап бирә.

Рита КОНДРАТЬЕВА,
Мөслим районы
Яңа Усы мәктәбенең
VII класс укучысы.



ТАРИХ ДӘРЕСЕНДӘ

УКЫТУЧЫ:

— Борынгы кешеләр, хәзерге кешеләрдән аермалы буларак, ничек яшәгәннәр? Йә, әйтеп кара әле, Илдар,— ди икән.

— Борынгы кешеләр диңгездә йөзгән кит балыгы өстендә яшәгәннәр. Без исә Кояш тирәсендә очып йөрүче Җир шарында яшибез,— дип җавап кайтарган Илдар.

Гөлнара ХӘМЗИНА,
VIII класс укучысы.
Буа шәһәре.


БҮГЕНГЕ ЭШ

ӘНИСЕ Маратка кибеттән шоколад алып кайткан. Марат шунда ук шоколад ашарга утырган.

— Улым, хәзер кибетләрдә шоколадлар юк. Шуңа күрә берьюлы ашап бетермә, иртәгәгә калдыр,— дигән әнисе.

— Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмыйлар,— дигән Марат.

Миләүшә ШӘЙГАРДАНОВА.
Актаныш районы
Иске Эгъбәз авылы.



ТӨШ

ИКЕ МАЛАЙ сөйләшә:

— Мин бүген төшемдә Казанга бардым.

— Ә мин бүген төшемдә зур чуртан тоткан идем, ләкин тартып чыгара алмадым.

— Нишләп мине чакырмадың, икәүләп ничек тә тартып алыр идек.

— Син Казанда идең бит.

Люция ХӘЙРУЛЛИНА,
Арча районы Кәче мәктәбе
укучысы.



...1945 елның 5 декабрендә АКШ диңгез авиациясенә караган 5 «Эвенжер» самолеты хәрби өйрәнүләрдән кайтып килә. Флорида ярымутравында урнашкан базада очыш белән идарә итүчеләр бервакыт звено командирыннан: «Без курстан чыктык, ахры. Җир бөтенләй күренми» дигән хәбәр ишетәләр. Диспетчерның көнбатышка таба очарга кушуына лейтенант Чарлз Тейлор: «Көнбатышның кайда икәнлеген белмибез. Сәер. Хәтта океан да гадәттәгечә түгел», — дип җавап бирә. Бераздан самолетлар белән радиоэлемтә бөтенләй диярлек өзелә. Җирдәгеләр очучыларның: «Алар безгә охшаганнар... Ак су эченә керәбез... Үләбез... Коткарыгыз...» дигән өзек-өзек сүзләрен генә ишетеп калалар.

Югалучыларны эзләргә Атлантик океанга хәрби корабльләр һәм экипажында 13 кешесе булган «Мартин Маринер» самолеты җибәрелә. Ул да билгеләнгән курска керә һәм... шул чордагы иң яхшы күзәтү приборлары белән коралланган самолет эзсез югала.

Атлантик океандагы хәзер Бермуд өчпочмагы дип йөртелүче урында югалган корабльләрнең һәм самолетларның саны меңнәр белән исәпләнә. Тагын шунысы да бар: корабльләр исән-имин калып, андагы кешеләрнең эзсез-нисез югалу очраклары да җитәрлек. 1872 елның ноябрендә «Дей Грация» дип аталучы инглиз корабы матрослары Бермуд өчпочмагында чайкалучы җилкәнле кораб күреп алалар. Шлюпкага утырып судноға барып килгән диңгезчеләр анда бер кешенең дә булмавын әйтәләр. Азык-төлек тә, төче су запасы да җитәрлек, акчалар, матросларның шәхси әйберләре, вахта журналы да үз урынында — кешеләр генә юк.

Серле өчпочмакка эләгеп исән чыгучылар да бар, әмма алар белән дә серле хәлләр булган. Әйтик, 1974 елда АКШның пассажир самолеты Майамидагы аэропортка төшәр алдыннан 10 минут локаторлар күзәтүеннән югалып торган. Самолет җиргә дә гадәттәгедән 10 минутка соңрак төшеп утыра. Очучылар үзләре вакытында килеп җиттек дип әйтәләр һәм сәгатьләренә күрсәтәләр. Тикшереп карагач, самолеттагы бар сәгатьләрнең дә җирдәгеләр белән чагыштырганда төп-төгәл 10 минутка соңга калуы ачыклана.

Океандагы шушы урында суның уннарча метрларга, хәтта километргача өскә күтәрелеп алуы да күзәтелә.

1963 елда Пуэрто-Рикадан Нью-Йоркка очучы самолеттагылар суның 30 секунд чамасы стена булып берничә йөз метрга күтәрелеп торуын күрәләр. Авиалайнер бу урынны узып киткәч, су тавы да ишелә башлый. Океан төбендәге җир тетрәгән яисә вулкан аткан дип уйлар идең — дөньяның сейсмик үзәкләре бу көнне бернинди дә җир тетрәү очрагын теркәмәгәннәр.

Шундый ук күренешләрне космонавтлар да күзәткән. «Салют-6» орбиталь станциясендә эшләгән Владимир Коваленок океандагы суның төрле урында төрле биеклектә торуы турында хәбәр итә. Валерий Рюмин белән Владимир Ляхов та Һинд океанында берничә километр биеклектәге «су тавы»н күрәләр.

Бермуд өчпочмагыннан бөтенләй читтә — Гонконг, Филиппин, Тайвань ярлары янында менә 600 еллар чамасы инде кораблар югала. Шторм вакытында түгел, ә менә җилсез, тыныч көннәрдә дә юкка чыгалар алар. Әйтик, 1950-54 елларда бу районда 9 кораб эзсез югалган, 1981 елда — өчәү. Шунысы кызык: алар исемлегендә шушы катастрофа сәбәпләрен ачыклау максатыннан җыелган галимнәр утырган «Кайо-Мару» судносы да бар.

Галимнәр Бермуд өчпочмагының серен әлегә кадәр аңлатып бирә алмыйлар. Берәүләр аны магнит полюслары белән аңлата, икенчеләре Җирнең тарту көченә бәйлиләр. «Оча торган тәлинкәләр» белән бәйләп аңлатучылар да юк түгел. Бу район галәмнән килүчеләрнең махсус аэродромы түгелме, янәсе.

Галимнәр өйрәнә тора, өчпочмакка эләгеп, һәлак булучы кораблар, самолетлар саны арта бара.

Англия язучысы Гилберт Честертонның түбәндәге сүзләре бар: «Серләрдә безне соклandырган иң зур әйбер — ул серләрнең булуы». Аларны ачыкларга теләп без табигать турында, үзебез турында күбрәк белергә омтылабыз.

(«Аврора» журналыннан алынды).



ҖӘЙНЕҢ ямьле бер көнендә без, бер төркем укучылар, Курск якларына сәяхәткә чыгып киттек. Моңарчы бу шәһәрне китаплардан гына укып белгән булсак, истәлекле урыннарын үз күзләребез белән күреп сокландык. Өстәвенә, Аркадий Гайдарның туган авылында булдык.

Безнең өчен шушы сәяхәтне оештыручы Нурия Мөбарәковнага һәм башка укытучыларга рәхмәт әйтәсебез килә.

Гөлфия ШӘЙБӘКОВА.
Башкортстан АССР
Исәмәт авылы.


ТАТАР ТЕЛЕН без барыбыз да яратабыз. Аны яхшы итеп өйрәнәсе килә. Шуңа күрә, киләсе уку елында безгә бу фәннән татар теле укытучысы керсә, бик шат булыр идек.

Сарман районы Иске Кәшер урта мәктәбенең VII-X класс укучылары.



Шушындый матур керпедән
Куркалардыр ник кенә?
Энәләре бигрәк йомшак —
Тотып торам бит менә!
Мин үзем дә аптырашта —
Авыртмый да, нитми дә.
Авырткангa, чәнечкәнгә
Минем исем китми лә!

Р. Мөгаллимов фоторәсеме.



Ямьле болын буйларында
Рәхәт болай йөрүе.

Абый фотога төшерде.
Беләм, бездән көлүе.

Гөлназ ХӘЛИУЛЛИНА,
Зеленодольск районы
Түбән Урысбага
мәктәбе укучысы.

Туганов абый яшереп куйган
Безнең киемебезне.
Без күлмәкләр эзләгәндә,
Төшереп алды безне.

Гөлнара ЮНЫСОВА,
Тәтеш районы
Зур Әтрәч мәктәбе
укучысы.

Ыштансыз калсак, калабыз,
«Яшь ленинчы» алабыз!

Гөлнара ГАБИДУЛЛИНА.
Казан шәһәре.

«Өч ыштансыз малай дөнья белән танышып йөргән идек бергәләп...»

Илнур ИХСАНОВ.
Сарман районы
Саклаубаш мәктәбе.

Базар экономикасына күчкәндә...

Айнур ЗЫЯТДИНОВ.
Казан шәһәре.

СПОРТ

СЕРЛЕ ГЕР


РӘШИТЛӘРНЕҢ өендә район, республика ярышларында яуланган күп санлы дипломнар, грамоталар, кубоклар бар. Алар кадерле урында — өй түрендәге шкафта саклана. Улларының нинди дә булса ярышта җиңүләре турында хәбәр китерсәләр, әниләре Әминә апаның гына түгел, әтиләре Исмәгыйль абыйның да күзләре яшьләнеп куя. Аның күзләрендә яшь бөртекләре белән беррәттән уллары өчен горурлану чаткылары да чагыла. Ә бит моннан 6-7 ел элек ата белән анага малайлары турында көндәлсез хәбәрләр генә китерәләр иде: «Сезнекеләр тагын сугышканнар!» «Әминә малае минем малаемны кыйнаган»... Хуҗалыктагы эшләрне җир җимертеп эшлиләр үзләре, тик менә туры килгәндә бәргәләшеп алырга да күп сорамыйлар. Яшелчәләр өлгергән чакта авылда алар кермәгән бакча бөтенләй калмый диярлек...

Беркөнне шулай бер авылдашы улларыннан зарланып килгәннән соң, гомере буе колхозда балта остасы булып эшләгән Исмәгыйль абый малайларын ишек алдына җыеп алды. Ул койма буенда күгәреп яткан ике потлы герне ишек алды уртасынарак чыгарып куйды.

— Көчегезгә чыдый алмасагыз, әнә гер күтәрегез,— диде ул малайларына ачу белән.

— Шул көннән соң без өчебез дә, бер-беребез белән ярыша-ярыша, спорт белән шөгыльләнергә тотындык,— дип сөйли Рәшит.— Тәмәке тартуны, теләсә кемгә бәйләнеп сугышып йөрүне бөтенләй ташладык.

Иң олылары Рафаил хәзер Питрәч районындагы Гаврилов исемендәге колхозның алдынгы тракторчысы, Күн авыл Советы депутаты. Авылдашлары аның янына киңәш сорап та, ярдәм сорап та еш киләләр, чөнки беләләр: Рафаил беркайчан да кеше гозеренә каршы килмәс. 1978 елдан бирле гер күтәрү һәм татарча көрәш буенча район чемпионы. Авырлыгы 60 килограммнан артмаган Рафаил Сафиуллин район гер күтәрүчеләре арасында абсолют беренчелекне дә үз кулында тота.



1985 ел аның хезмәт биографиясендә дә, спорт биографиясендә дә уңышлы ел булды. Бишьеллыкның соңгы, тәгәлләүче елында ул районның яшь механизаторлары арасында барган социалистик

ярышта җиңеп чыкты. Ә татарча көрәш буенча «Социалистик Татарстан» газетасы үткәрә торган ярышларда да, Татарстан беренчелегендә дә тиңнәр булмады аңа. Шулай итеп ул Сафиуллиннардан беренче булып «Милли көрәш буенча РСФСРның спорт мастеры» исемен алды. Гаврилов исемендәге колхоз спортчылары соңгы елларда Питрәч районында алдынгылардан саналалар. Монда Р. Сафиуллинның да өлеше зур. Колхоз күләмендә үткән һәр ярышны башлап йөри ул, үзе әйтмешли, «колхозның штаттан тыш спорт инструкторы». Минемчә, менә шундый егетләр булганда безнең күп кенә колхозларыбызда спорт эше гөрләп барыр, авыллардан шәһәргә китүчеләр дә кимер иде.

Сафиуллиннарның икенчесе — Рәшит Казанның Ленин районы эчке эшләр бүлегендә эшли, спортның йөгерү, көрәш, гер күтәрү, чаңгыда йөрү кебек төрләре белән шөгыльләнә. Ул 100 һәм 200 метрга йөгерүдә «Динамо» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан чемпионы. Менә дүрт ел инде Күн авылы сабан туенда көрәш буенча аңа тиңнәр юк. Спорт белән шөгыльләнү Рәшиткә эшендә дә һәрчак ярдәм итә.

— Бервакыт кыш көне трамвай тукталышында ялан башлы бер егет күзгә чалынды,— дип сөйли ул.— Кыйммәтле бүреген талап киткәннәр икән. Шактый озак йөгергәннән соң гына куып җиттем бүрек карагын. Физик яктан бик таза иде — бераз әүмәкләшергә туры килде. Ул кайчандыр спорт белән шөгыльләнгән, ә хәзер беркайда да эшләмәүче эрәмтамак булып чыкты. Элегрәк тә шундый юл белән берничә кешенең бүреген салдырып алып качкан булган, куып тота алмаганнар. Бу юлы да качып котылырмын дип уйлаган дыр.

Рәшит узган ел иң элек милли көрәш буенча Татарстан беренчелеген отты, аннан Россия батыры булды. Шулай итеп, ул Сафиуллиннар гаиләсендәге икенче спорт мастеры булды.

Әнә хәзер өченче малай — Рәис тә чын-чынлап көрәш, чаңгы, йөгерү, гер күтәрү спорты белән шөгыльләнә. Ул да Казанның Киров районы эчке эшләр бүлегендә эшли. Күптән түгел генә спорт мастерлыгына кандидат нормасын үтәде.

...Исмәгыйль абыйларның ишегалдында теге гер һаман ята әле. Кайчакта аны дүртенче класста укучы оныгы Ленар тәгәрәтеп уйнап йөри. Бервакыт тимер-томыр җыйганда шунда тапшырыйкмы әллә дип тә сорады бабасыннан. «Ашыкма, улым,— диде бабасы.— Бик серле, бик кыйммәтле гер бу. Азрак үсә төш әле, аның серен үзең дә ачарсың».

А. ГАФИЯТОВ.

Рәсемдә: Рәшит, Рафаил, Рәис Сафиуллиннар.
Н. Седов фоторәсеме.



«ИТИЛЬ» уйный

Казан хоккей командасының шулай аталуын сез беләсез инде. Югары лигада быелгы хоккей сезоны ачылуга да айдан артык вакыт узды. Якташларыбыз дистәгә якын уен үткәрергә өлгерделәр. Әмма әлегә хәлләр бер дә мактанырлык түгел. Безнең команданың нибары 4 очкосы бар. Ул 15 коллектив арасында унөченче урында бара.



СӨЕНДЕРӘСЕҢ ГАТА!

БЕЗНЕҢ ИЛДӘ шулай: киткәннәрне гадәттә хурлап калалар. Гата Камский белән дә шулай булды. Ул әтисе белән Америкада торып калгач, аның адресына нинди генә хурлау сүзләре әйтелмәде: «Сүнәчәк», «Моннан соң әйбәт уйный алмаячак»...

Ләкин бу юрауларның берсе дә чынга ашмады. Гата үзе булып калды. 14 яшендә шахматта халыкара гроссмейстер исемен яулады. Ирләр арасында мондый дәрәҗәгә ирешүчеләрнең иң яше ул. Чагыштыру өчен шуны әйтергә була. Американың мәшһүр шахматчысы, элеккеге дөнья чемпионы Роберт Фишер бу дәрәҗәгә 15 яшендә ирешкән иде.

Шушы көннәрдә генә Тильбург шәһәреннән куанычлы хәбәр килде. Дөньяның берничә иленнән килгән иң көчле шахматчылар ярышында Гата беренче-икенче урынны бүлеште.

Сөендерәсең, Гата! Киләчәктә дә сынатма!

Рәсемдә: Гата Камский.

Р. Галиев фоторәсеме.

Әхмәт Рәшиди

БОРЧАК ҺӘМ ТУГЫЗ КАПКОРСАК



Безнең борчак кырында
Тугыз симез капкорсак
Уздырыша-уздырыша
Чүпләп йөри яшь борчак.

Беренчесе бирән ди,
Инде ачтан үләм, ди,
Икенчесе исәр ди,
Бертуктамый күшәр ди,
Өченчесе өтек ди,
Кигән тишек читек ди,
Дүртенчесе — дивана,
Ни борчак, ни корт аңа,
Бишенчесе биштәрле,
Биштәрендә — биш тәре.
Алтынчысы ахмак ди,
Кабатлый гел такмак ди:
— Борчак, борчак,
капкорсак,
Безнең корсак —
шәп корсак...
Җиденчесе... җирән ич!..
Үзе бигрәк җирәнгеч,
Сигезенчесе симез ди,
Ашый көнгә сигез ди,
Тугызынчысы туймас ди,
Борчакны һич куймас ди.

Тугыз ачкүз — капкорсак
Ашыйлар ди, һәй, борчак.
Безне дә кабып йотарлар,
Авыз ачып тик торсак.

Дидек тә без, малайлар,
Җыелышып киңәштек,
Капкорсакларны
борчактан
Биздерергә сөйләштек.
— Әгәр алтатар корсак...
— Көпшәсен кырга борса..
— Куркытып тамак кырса.
Нишләр тугыз капкорсак?

Алтатарны кордык без,
Аны кырга бордык без,
Тамакларны кырдык без,
Куркырлар дип тордык без,
Курыкмады берсе дә...
Нилектән? Сәбәп нидә?..
Алтатар, дип, аның без,
Белмәгәнбез җаен без...
Борчак белән корганбыз,
Кире якка борганбыз.

Аптырашып тордык та,
Дары салып кордык та,
Ут кабынып ялт итте...
Һәм алтатар шарт итте.
Шуннан тугыз капкорсак
Тотындылар чабарга,
Ныграк курыксыннар, дип,
Без калмыйбыз алардан.
Капкорсаклар, әй, чаба...
Чаба Каф-тауга таба.
Бирән берзаман арып
Бишмәтен атты салып,
Исәр иске ыштаннан,
Ычкырлары бушаган,
Тишек башлы читек тә
Төшеп калды өтектән,
Бишенче — күр! —
нишләве...
Тишек икән биштәре,
Үзе «ах!» иткән була —
Борчаклары коела,
Ахмак инде ул — ахмак —
Кабатлый һаман такмак:
— Борчак, борчак,
капкорсак,
Безнең корсак —
шәп корсак...
Җирән, симез һәм туймас
Инде килергә кыймас —
Капкорсаклар —
әт-тә-тә! —
Котлар очкан, әлбәттә,
Чабалар абына-абына
Туп-туры Каф тавына.

Ә анда, Каф тавында
Утыра ялгыз гына
Корсагын кашый-кашый
Аждаһа — тугыз башлы.
Шунда, күреп алды да
Капкорсаклар узышын,
Берәм-берәм кабып йотты
Тугыз башы тугызын.

Без шаккатып тордык та
Кире чаптык авылга.
Без күргән бу маҗара
Онытылмас, дип, мең ел да.
Бөтен халык бу хәлне
Көлә-көлә тыңлады!
Тик нигәдер беркемне
Ышандырып булмады.

Берчак борчак өлгерде —
Җыеп алдык яхшылап,
Амбарларга ташыдык
Һәм куйдык җиңел сулап.
Тегермәндә тарттырып
Пешекчегә бирделәр,
Бөтен авылга җитәрлек
Чумара пешерделәр.
Бигрәк тәмле чумара, дип,
Әллә кемнәр сөйләде.
Бөтенесе сыйланды, тик
Миңа гына тимәде.





РӨСТӘМ АНЫ дүртенче класска укырга килгәч күрде. Ул мәктәпкә, башкалар шикелле әти-әнисе белән түгел, эте белән килде. Эт аларның концертларын тыңлап торды, аннары Камил аңа кайтырга кушты. Муйнак карусыз кайтып китте.

Класска кергәч, укытучы Рөстәмне Камил белән утыртты. Алар партадаш булдылар. Укучылар тәнәфесләрдә өйдән алып килгән ризыкларын ашаганда, Камил коридорга чыгып китә иде. Рөстәм аңа карап йөрде дә беркөнне өйдән алып килгән ипиенең яртысын партадашына тоттырды. Камилнең күзләре очкынланып китте, Рөстәмне үзе белән тышка алып чыкты. Бер сызгыруы булды, эт очып килеп җитте. Камил Рөстәмгә карады да:

— Мин ипиемнең әзрәген Муйнакка бирим, ул иртәдән бирле ач,— диде ул.

Рөстәм рөхсәт иткәч, ул бөтен ипиен дә этенә ашатты.

— Беләсеңме, ул өйрәтелгән. Яле, Муйнак, арт аякларында тор әле.

Эт шунда ук арт аякларына басты. Камил җирдән бер таяк алды да аны каядыр читкә ыргытты. Эт таякны да барып алып килде. Рөстәм көлеп җибәрде. Боларны күзәтеп тору аңа кызык иде.

Камил Рөстәмнең иң якын дустына әйләнде. Беркөнне Камил аны үзләренә чакырды. Дусты әйткән йорт янына килеп җиткәч, Рөстәм аптырап китте: аның каршында җимерелергә торган өй иде. Башта керергәме, кермәскәме дип уйлап торды. Аннары бер карарга килеп, ишегалдына таба атлады. Анда Камил тавыклар ашатып йөри иде. Рөстәм: «Әниең авырыймы әллә?»— дип сорап куйды.

— Берәүгә дә әйтмисеңме? — диде Камил. Вәгъдә алгач, атасының үлгәне, анасының аларны ташлап китүе, әбисе белән икәү генә яшәүләре турында сөйләде.

— Якын дустым — Муйнак инде минем,— дип төгәлләде ул сүзен.

Бервакыт алар авылына аучылар килеп чыкты. Бәйсез этләрне атарга керештеләр. Камил йокыдан торганчы Муйнакка атып, аягын аксатканнар иде. Ярый әле качып өлгергән. Шул көннән башлап Камил мәктәпкә килмәде. Рөстәм тагын партадашының хәлен белергә китте.

Дустын елга буенда яралы этен кочаклап утырган хәлдә тапты Рөстәм. Икенче көнне Муйнак үлде.

Һич көтмәгәндә Камилнең әбисе үлеп китте. Бу кайгыдан соң Камил нишләргә дә белмәде. Рөстәм дә, күрше малайлары да аны төрлечә юатырга тырыштылар. Әбисен җирләгәч, Камилне күршеләре балалар йортына бирергә теләделәр. Ләкин Камил ризалашмады, иске өйдә үзе генә тора бирде. Дусты Рөстәм аны бер минутка да ташламады: бергәләп укырга йөрделәр, укудан соң балыкка баралар иде.

Җәйнең соңгы көннәре иде. Көтмәгәндә авылга Камилнең әнисе кайтып төште. Улын алырга кайткан иде ул. Хәзер Рөстәмгә дустыннан хатлар гына килә. «Монда күңелле, ләкин синең янга, авылга бик кайтасым килә»,— дип яза ул. Рөстәм ышана, балачак дусты белән кабат очрашасына ышана.

Әнисә ГАЛИӘХМӘТОВА,
Арча районы Югары Пошалым мәктәбе укучысы.



Хәтерегездә булса, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре М. Ш. ШӘЙМИЕВ КПСС Үзәк Комитетының 1990 елгы март Пленумында ясаган чыгышында: *«Соңгы вакытта абруйлы басмаларның кайберләрендә, мәсәлән, илебез тарихында татар халкының тискәре ролен исбатлау куертыла. «Правда» битләрендә, русларның ата-бабасын катнаштырып сүгенүе татарлар йогынтысы нәтиҗәсе ул, дип исбатлана. «Советская культура», рус теле — борынгы татарлар авазы ул, дип ышандырырга маташа. «Известия» газетасы» «Социализм — ул рус-еврей башкаруында татар-монгол изүе» дигән ачыш ясый»*,— дигән иде.

Шуңа да карамастан, татар милләтен төрлечә хурлау, төрлечә мыскыллау һаман да дәвам итә. Каршымда «Советский художник», «Изобразительное искусство» нәшриятында әле күптән түгел генә чыккан открыткалар ята. Шуларның берничәсенә язылган җөмләләрне сезгә дә китерәсем килә: *«Убил в поле трех татаринов, трех собак наездников»*,

«...Вещает иго злых татар,
Вещает казней ряд кровавых,
И трус, и голод, и пожар,
Злодеев силу, гибель правых...»

Билгеле, безнең үләсе дә, эт тә буласы килми.

Күпме генә сөйләсәк тә, күпме генә зарлансак та, милләтебезгә пычрак атучыларны туктатып булмый. Эт өрә тора, бүре йөри тора, диләрме әле? Монда да нәкъ шул. Ләкин моңа чик куелырга тиеш. Пычрак атучылар законнар аша туктатылырга тиеш. Мин әлеге мыскыл итеп, татар халкына пычрак ягып язылган газета-журналларны, открыткаларны җыям, аларны тиешле органнарга тикшерергә җибәрәчәкмен. Укучылар! Бу эштә сез дә ярдәм итегез әле миңа. Татар милләте турында ямьсез сүзләр язылган, дөрес булмаган фикерләр әйтелгән сүзләрне кисеп алыгыз да минем адреска җибәрегез:

422550, ТССР,
г. Зеленодольск,
ул. Карла Маркса, 65-36.
Биктагирову Фидаилю Гарифовичу.



Бүгенге Казан.

Н. Седов фоторәсеме.



КЕРФЕКЛӘРЕҢ НИГӘ КАРА БУЛГАН...

КАШ һӘМ КЕРФЕКЛӘР битне матурлап кына калмыйлар, балакайларым. Керфекләр күзләрне җилдән, тузаннан, кашлар — яңгыр суының маңгайдан турыдан-туры күзгә агып төшүеннән саклыйлар. Шуңа күрә керфек, кашларның үзләрен дә сакларга, тәрбияләргә кирәк.

Керфекләр авырмасын өчен күз почмаклары чиста булырга тиеш. Күзне һич тә кул белән уарга ярамый: кулдан ягылып калган пычрак күзнең кызаруына, күз кабакларының ялкынсынуына сәбәпче булуы мөмкин. Үз сәламәтлегенә битараф булмаган кеше беркайчан да чиста кулъяулыксыз йөрмәс.

Күзләрне вакыт-вакыт бор суы (бер стакан кайнаган суга бер бал кашыгы борат кислотасын эретәсең) яки ромашка чәчәге төнәтмәсе (бер аш кашыгы кипкән чәчәкне бер стакан кайнар суда пешерәсең) белән юарга кирәк.

Күп кенә кызлар башкаларга кызыгып кирәк-кирәкмәгәнгә кашларын йолка. Кашлар ыкчым, пөхтә икән, аларны йолку һич кирәк түгел. Чөнки бер йолка башласаң, кашны гел йолкып матурлап торырга кирәк була. Кашны йолыкканнан, кырганнан соң үскән төкләр катырак, күзгә бөгелеп торучан булалар. Шулай да, алар күз өстеннән салынып торсалар, кашның аскы өлешендәге төкләрне махсус эскәк белән йолкыгыз.

Кашларны үстерү, ныгыту өчен 30 грамм касторка маена 15 грамм көнбагыш, 5 грамм камфара майларын кушып каш бөртекләре төбенә ышкып сөртү файдалы.

Зөһрәбикә әбиегез.

СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?

КОЯШТА — АЛТЫН

КАЙБЕРЛӘРЕГЕЗНЕҢ «Кояшның алтын кысасы» дигән тәгъбирне ишеткәне бардыр. Без аны болай гына әйтелгән сүзләр дип белә идек. Ә менә Каир университеты астрономы Нахед Йосыф күп еллар буе күзәтүләреннән һәм тикшеренүләрдән соң бу тәгъбирнең дөреслеккә туры килүен ачыклады. Кояш тышлыгындагы 12 водород атомына бер алтын атомы туры килә икән. Димәк, Кояш янында алтынның меңнәрчә тонна запасы бар.

АКЫЛЛЫ ТОТКА

АМЕРИКАДАГЫ бер фирма ачкычсыз һәм хәтта төймәсез йозак эшли. Ишек тоткасына тотынып аны үзең алдан билгеләп куйган кадәрле як-якка борырга гына кирәк. Әйтик, уңга — 2 тапкыр борасың, аннан соң сулга бер тапкыр... һәм ишек ачылып китә.

ЯЗУ МАШИНКАСЫН — АГАЧТАН

ДРЕЗДЕН шәһәрендәге бер музейда тулысынча агачтан ясалган язу машинкасы саклана. Аны 1964 елда Тироль шәһәре балта остасы Питер Миттенхофен ясаган.

ГАЗЕТАБЫЗ БИТЛӘРЕННӘН

60 ел элек

Без, Норлат төбәге Кече Шырдан авылы укучы һәм пионерлары, ярдәм комитетының арышларын урыштык. Хәзер көлтәләрне кертеп сугарга хәзерләнәбез.

Керәстиян агайлар бик зур рәхмәт укыйлар.

Деткор.
(1930 ел, 21 август).

30 ел элек

VII класс пионеры М. Сабитов 150 килограмм тимер-томыр җыеп, мәктәп бернчелеген алган классташы Ш. Шагаев белән ярышка чыкты. Һәм Шамилны уздырды: 209 килограмм металл ватыгы тапшырды.

Мидхәт ялгыз түгел. Ул урамда уйнап йөрүче 4-5 яшьлек малайларны да үзенә ияртә. Кечкенә балалар аңа 20 кг тимер-томыр җыешканнар.

Дружина советы члены Мидхәт Сабитов КПССның XXII съезды хөрмәтенә тагын 200 килограмм металл ватыгы әзерли.

С. БӘДРЕТДИНОВ, колхозчы.
Чүпрәле районы Зур Чынлы авылы.

(«Яшь ленинчы», 15 июль 1961 ел).

20 ел элек

Мин класста Изһария Камилова белән ярышам. Ул — отличник, мин — ударник. Мин аны куып җитү өчен тырышам. Безнең классның башка укучылары да шулай ярышып укыйлар. Артта калучыларга ярдәм итәбез.

Роза САМАТОВА,
III класс укучысы.
Актаныш районы Иске Кормаш сигезьеллык мәктәбе.

10 ел элек

Илебез халкы коммунизмга бару юлында ышанычлы адымнар белән 1980 елга атлап керде.

(1980 ел, 5 январь).



Заказ 79.

КПССның Татарстан республика комитеты типографиясендә басылды.

Редактор
Роберт МИҢНУЛЛИН.